

# Чишмә

52 НЧЕ ТАТАР УРТА ГОМУМ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ

№63






Нәни дус!

Син атлаган юлларга
Алтын яфрак сибелә.
Чыңлый көмеш кыңгырау,
Дәшеп белем иленә.

Бик күп нәрсә белерсең син
Туган илең турында.
Син бит хәзер бик зур кеше –
Әлифбаң бар кулыңда.

Белем көне белән, дустым,
Омтыл һәр көн белемгә!

Кадерле укытучылар, тәрбиячеләр, әни-әтиләр, укучылар, быел беренче мәртәбә мәктәп бусагасын атлап керүчеләр!

1 сентябрь халыкның гомуми бәйрәме булды һәм шулай булыр да. Әлеге көн һәркем өчен бердәй кадерле, якын. Балачак, үсмерчакның иң якты хатирәләре мәктәп еллары белән бәйле. 1 сентябрь – ул укытучы, педагог, тәрбиячеләр белән дулкынландыргыч очрашулар булган өчен кенә түгел, буяу исе килеп торган парта, идән, диварлары белән сезне көтеп торган көн буларак та кадерле.

Мәктәп бусагасын яңа уку елында 601 бала атлап керәчәк.

Әлеге бәйрәм көнендә барлык укучыларга белем нигезләрен тырышып, кызыксынып үзләштерүләрен телибез.

Быелгы уку елы яңа иҗади ачышлар һәм җиңүләр елы булсын. Сезгә нык сәламәтлек, бәхет, хыялларыгызның тормышка ашуын телибез. Бәйрәм белән! Хәерле сәгатьтә!

**Алтын сукмак буйлап көз атлый...**

Табигатьтә көз-патшабикә хакимлек итә. Ул тирә-як әйтеп бетерә алмаслык гүзәллеккә чумдырды. Агач яфракларына сарылган алтынсу-кызыл, шәмәхә төсләр бөтен дөньяга бәйрәм төсе бирә. Сукмакларга түшәлгән шул яфраклар бәрхет келәмнәрне хәтерләтә. Паркта шул яфрак өсләреннән атлаганда аларның шыгыр-шыгыр итеп куюы җанга рәхәтлек бирә.

Көз-патшабикәнең әмере белән бакчаларда җиләк-җимешләр өлгерә. Алма бакчаларында өлгереп җиткән алмалар “Мине өз, мине”, – диеп, авыз суларын китереп торалар. Без аларны җыеп алабыз, әниләр алардан кышка төрле салатлар, кайнатмалар әзерли. Бөтен кышка җитәрлек витамин җыела.

Ә кошлар... Кошлар исә, төркем-төркем җыелышып нидер сөйләшәләр кебек. Зәңгәр күктә тезелешеп очкан кошларның, туган җирләрен калдырып, җылы якларга китәр вакытлары җитә.

Мәктәп бакчасындагы аллы-гөлле чәчәкләр ямь өстенә ямь өстәп торалар. Мәктәп бакчасында һәр сыйныф үзенә бирелгән урынны чистарта, тәртипкә китерә.

Туган җиремдә алтын сукмак буйлап көз атлый...


Илфира Йосыфова, 7 нче а



Мин көзне яратам. Чөнки көзен бөтен табигать матур төскә керә. Бу ел фасылында бакчада эшләр күп була. Минем әбием һәм бабам авылда яши. Аларның зур бакчалары бар. Без көз көне бөтен гаиләбез белән аларга бакча эшләрендә булышабыз.

Җиләк-җимешләрне җыябыз, агачларны тәрбиялибез, яңа агачлар утыртабыз , бәрәңге алабыз, йорт алларын җыештырабыз. Әбием һәм бабама мин бик теләп булышам.

Марсель Галиев, 5 нче а сыйныфы укучысы



Минем өчен көз – моңсу ай. Чөнки матур җәй айлары, каникуллар бетә. Укулар башлана. Укырга яратсам да, ял итү барыбер рәхәтрәк. Аннары, көз көннәр салкыная, көннәр кыскара башлый. Караңгы иртә төшә. Яңгырлар ява. Ләкин көзнең ошаган яклары да бар. Бөтен табигать матур сары төскә керә.Дәреслэрдән соң, шәһәр паркында коелган яфракларны җыюы, атлаганда аларның кыштырдавы ошый.

Ләйсән Гареева, 5 нче а сыйныф

Һәркемнең яраткан ел фасылы була. Күп укучылар җәйне ярата. Җылы булганы, каникуллары өчендер инде. Ә миңа көз ае ошый.

Быел туган шәһәремә көз бик иртә килде. Инде август башларында ук ук ул үзенең җилләре-яңгырлары, салкыннары белән зур-зур адымнар атлап, көз килеп тә җитте. Август ае салкын булса да, сентябрь безне матур җылы көннәре белән сөендереп кенә торды. Һәркөнне диярлек “Әбиләр чуагы” икәнен белдереп, кояш елмайды, битне пәрәвез җепләре иркәләде. Мәктәптә укулар тәгәлләнгәч, шәһәр паркына юл тотам. Зәңгәр күктә зур ак пароходлар кебек болытлар, узыша-узыша каядыр чабалар. Җиргә түшәлгән йомшак алтын яфраклар, әйтерсең, келәмнәрне хәтерләтә. Ә агачлар!? Берсен-берсе уздыра-уздыра җәйге киемнәрен көзгегә алмаштырганнар. Һәрберсе күз явын алырлык. Сары, кызыл, алтынсу төсләр хакимлек итә бирелә. Кинәт кенә бозыла башлый. Җил битне чеметеп-чеметеп ала. Шул арада куркыныч болытлар да хасил була. Мин тизрәк өйгә ашыгам. Тиз генә өйнә кайтып керәм дә, тәрәзә төбенә утырып, бертуктаусыз пыскып-пыскып яуган яңгырны күзәтәм. Урам буп-буш диярлек. Ара-тирә генә, яңгырга юешләнмәс өчен, тиз-тиз генә өйләренә чабучы апа-абыйлар, кулчатырлары астына яшеренгән әби-бабайлар күренгәли.

Көз – иң матур ел фасылы. Ләкин аның матурлыгын күрә белергә генә кирәк.

Эльвира Мөхәммәтханова, 9 нчы б сыйныфы укучысы

# 2019-2020 уку елына календарь

| | Сентябрь | | | | | | Октябрь | | | | | Ноябрь | | | | | Декабрь | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Пн | | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 | | 7 | 14 | 21 | 28 | | 4 | 11 | 18 | 25 | | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| Вт | | 3 | 10 | 17 | 24 | | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 | | 5 | 12 | 19 | 26 | | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 |
| Ср | | 4 | 11 | 18 | 25 | | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 | | 6 | 13 | 20 | 27 | | 4 | 11 | 18 | 25 | |
| Чт | | 5 | 12 | 19 | 26 | | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 | | 7 | 14 | 21 | 28 | | 5 | 12 | 19 | 26 | |
| Пт | | 6 | 13 | 20 | 27 | | 4 | 11 | 18 | 25 | | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 | | 6 | 13 | 20 | 27 | |
| Сб | | 7 | 14 | 21 | 28 | | 5 | 12 | 19 | 26 | | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 | | 7 | 14 | 21 | 28 | |
| Вс | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 | | 6 | 13 | 20 | 27 | | 3 | 10 | 17 | 24 | | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 | |

| | Январь | | | | | Февраль | | | | Март | | | | | Апрель | | | | Май | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Пн | | 6 | 13 | 20 | 27 | 3 | 10* | 17 | 24 | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 | 6 | 13 | 20 | 27 | 4 | 11 | 18 | 25 |
| Вт | | 7 | 14 | 21 | 28 | 4 | 11* | 18 | 25 | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 | 7 | 14 | 21 | 28 | 5 | 12 | 19 | 26 |
| Ср | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 | 5* | 12 | 19 | 26 | 4 | 11 | 18 | 25 | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 | 6 | 13 | 20 | 27 |
| Чт | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 | 6* | 13 | 20 | 27 | 5 | 12 | 19 | 26 | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 | 7 | 14 | 21 | 28 |
| Пт | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 | 7* | 14 | 21 | 28 | 6 | 13 | 20 | 27 | 3 | 10 | 17 | 24 | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| Сб | 4 | 11 | 18 | 25 | 1 | 8* | 15 | 22 | 29 | 7 | 14 | 21 | 28 | 4 | 11 | 18 | 25 | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| Вс | 5 | 12 | 19 | 26 | 2 | 9* | 16 | 23 | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 | 5 | 12 | 19 | 26 | 3 | 10 | 17 | 24 | |

- Каникуллар
- Беренче сыйныфлар өчен каникуллар
- Дәүләт

| | |
|---|---|
| Государственные праздничные выходные дни | 30 августа – День Республики Татарстан |
| | 4 ноября – День народного единства |
| | 1 января – Новый год |
| | 7 января – Рождество Христово |
| | 23 февраля – День Защитника Отечества |
| | 8 марта – Международный женский день |
| | 1 мая – Праздник Весны и Труда |
| | 9 мая – День Победы |
| | 24 мая – Ураза-байрам |
| | 12 июня – День России |
| | 31 июля – Курбан-байрам. |

**Безнең адрес: 423827, Яр Чаллы шәһәре, Яңа шәһәр, 52\36, 52 нче татар гомум белем бирү мәктәбе**

Телефон: (8552) 59-36-88

**Без Вебта: https://edu.tatar.ru/index.htm/sch52/page1067817.htm**

## Уку көннәре

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 четверть | 1-10 сыйныфлар | 8 атна | 02.09 - 29.10.2019 |
| 2 четверть | 1-10 сыйныфлар | 8 атна | 07.11-26.12.2019 |
| 3 четверть | 2-10 сыйныфлар | 10 атна | 09.01-22.03.2020 |
| | 1 сыйныфлар | 9 атна | 09.01-4.02.2020<br>12.02-22.03.2020 |
| 4 четверть | 1 сыйныфлар | 8 атна | 01.04-22.05.2020 |
| | 2-8,10 сыйныфлар | 8 атна | 01.04 - 30.05.2020 |
| | 9 сыйныфлар | 8 атна | 01.04-21.05.2020 |
| ИТОГО | 1 сыйныфлар | 33 атна | |
| | 2-10 сыйныфлар | 34 атна | |